# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Аю торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**22.11.2024 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Аю торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм Аю торак пунктында яшәүчеләргә су бирүне (скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу) тәэмин итү;

2) Аю торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ремонтлау;

3)Аю торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (трактор өчен янгынга каршы тагылма җайланма сатып алу һәм җиткерү).

3.Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге башлыгы ________ А.М.Галимов